МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.02.2021 г.Казань № 114

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 19 мартында 7602 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы белән расланган Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 15.05.2018 №366, 18.09.2018 №886, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652, 12.11.2019 №984, 06.07.2020 №488, 08.10.2020 №711 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Акланган

гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 114 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы белән расланган Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.4 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләүгә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыгракка түгел.»;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында (вәкаләтле органда)»;

2.7 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча

чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Нигезләмәнең 8.3 пункты»;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү»;

3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

Үзәк бүлеге белгече шәхси счетның (Россия Федерациясе Пенсия фондында) иминият номеры турында электрон формада мәгълүмат ала.

Бүлекчәдә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаганда, Үзәк белгече ведомствоара электрон багланышлар системасы аша вәкаләтле органнан шәхси счетның иминият номеры (Россия Федерациясе Пенсия фондында) турында, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы (булмавы) турында электрон формада белешмәләр соратып ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.4, 3.5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 4 нче һәм 6 нчы кушымталары нигезендәге электрон рәвештәге формалар буенча чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.4.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар.

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту яки чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.4.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләре алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлеге белгече:

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы карар проектларын Үзәкнең бүлек җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны

җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карарлар проектлары.

3.4.4.2. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салмаган очракта, чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, Үзәкнең бүлек белгече чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында гариза бирелгән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.4.5. Үзәк бүлеге җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карар проектларын яисә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы карар проектларына яисә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турындагы карар проектына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм чыгымнарны кайтаруны билгеләү яки чыгымнарны кайтаруны билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

3.4.6. Үзәк бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан чыгымнарны кайтаруны билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау юлы белән) чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында хәбәр итү, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.»;

3.7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

3.7.1 пунктта:

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерә» сүзләреннән алда «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проектын яки» сүзләрен өстәргә;

дүртенче һәм бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын яисә чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәү көненнән соң килүче бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.7.2 пунктта:

беренче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

3.7.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.3. Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яисә чыгымнарны кайтаруны билгеләү турында карар турында хәбәр итү.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акланган граждannарга телефон урнаштыру буенча чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Үзәкнең №____ бүлеге

___________________________

муниципаль районында (шәһәрендә)

ГАРИЗА

№____________________________ «___» _____________ 20______ ел.

Мин, _________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_________________________________________________________________________

яши торган адрес

_________________________________________________________________________

(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

| Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

СНИЛС (алучыныкы) _______________________________________________________

Эш итү нигезе __________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауны раслаучы документ реквизитлары)

1. Телефон урнаштыруга киткән чыгымнарны кайтаруыгыз турында үтенәм

_________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

2. Билгеләнгән түләүне түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

счетка күчерү юлы белән

_________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлекчәсе аша ________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Гаризага түбәндәге документларны (күчермәләрен) һәм белешмәләрне терким:

| Т/с | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

3. Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ________________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

4. Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында мәгълүмат алуга риза:
әлеге адрес буенча язмача формада ________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________________

(телефон номеры буенча)

электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ____________________________

(электрон почта адресы)

Мөрәҗәгать итүче ___________________________________
«__» __________ 20__ ел. Имза ______________________
Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ______________________________

___________________________________________________________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

___________________________________________________________________________

Аеру линиясе
Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ___________ _________ ____________20__ ел.

___________________________________________________________________________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акланган гражданнарга
телефон кертүгә киткән
чыгымнар каплау өчен түләү
билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

РМЯҮ (КТ) №_____
бүлеге_____________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Социаль ярдәм чараларын билгеләү (бирү) турында карар

№______ «______» __________

Алучының Ф.И.А. ________________________________________________________
Алучының адресы ________________________________________________________

Билгеләргә (бирергә):

| N | Социаль ярдәм чаралары | Түләү күләме | Билгеләнү датасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнарын кайтару | | |

Түләү ысулы ______________________________________________________________
Бүлек җитәкчесе ________________________ ______________________________
(Ф.И.А.) имза
мөһер урыны
Бүлек белгече ________________________ ______________________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
язмача
телефон аша __________________________
телефон номеры
факс буенча __________________________
факса номеры
электрон почта буенча ______________________________
электрон почта адресы
бүлек белгече ___________________________ ________________
(Ф.И.А.) имза

РМЯҮ (КТ) №_____
бүлеге_____________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

«_____» ___________ 20_____ ел. №_______

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20___ елның «___» _______ боерыгы белән расланган Акланган гражданнарга телефон урнаштыруга чыгымнарны кайтаруны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентның 2.8 пункты нигезендә акланган гражданинга телефон кертүгә киткән чыгымнарны кайтару буенча түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга_______________________________________________.

Баш тарту сәбәбе: ____________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Бүлек җитәкчесе ____________________ ________________
(Ф.И.А.) имза м.у.
Бүлек белгече ____________________ ________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
язмача
телефон аша ____________________
телефон номеры
факс буенча ____________________
факса номеры
электрон почта буенча _________________________
электрон почта адресы
бүлек белгече ______________________ ______________
(Ф.И.А.) имза»;

регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

форма

РМЯУ (КТ) №_____
бүлеге___________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,_____________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес _________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
_________________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________________________________,
_________________________________________________________________________________,
(кирәклесе астына сызарга):
акланган гражданнарга телефон урнаштыруга киткән чыгымнарны кайтаруны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында ______________________№____ карарда җибәрелгән.
(карар датасы) (карар номеры)
акланган гражданнарга телефон урнаштыруга киткән чыгымнарны кайтаруны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында ______________№_________ карарда җибәрелгән.
(карар датасы) (карар номеры)
Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында мәгълүмат алуга риза

_________________________________________________________________________
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)

«____» ___________ 20_______ел. _____________________ _____________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта өстәргә:

«Акланган гражданнарга телефон
кертүгә киткән чыгымнар каплау
өчен түләү билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

форма

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге ДКУ №___ бүлеге ______________________ муниципаль районында (шәһәр округында)

Акланган гражданнарга телефон урнаштыруга киткән чыгымнарны кайтаруны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында
КАРАР

№________ «________» _____________

Мөрәҗәгать итүченең ФИА ______________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы______________________________________________________
______________________________________________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу сәбәпле, бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр, акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатырга, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк чорга түгел.

Бүлек җитәкчесе_____________________________ ______________ ________________
(Ф.И.А.) имза М.У.

Бүлек белгече ____________________________________
(Ф.И.А.) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:

Язмача __________________________________________
почта адресы буенча

sms-хәбәр итеп _______________________________
телефон номеры

электрон почта буенча _______________________________________
электрон почта адресы

Бүлек белгече _______________________________
(Ф.И.А.) имза»;

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ бүлекчәсе

__________________________________________

______________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Акланган гражданнарга телефон урнаштыруга киткән чыгымнарны кайтару буенча түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында
КАРАР

№____________ «_________» _____

Мөрәҗәгать итүче Ф.И.А. __________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы___________________________________________
________________________________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны җайга салу белән бәйле рәвештә, акланган гражданнарга телефон кертүгә чыгымнарны кайтару буенча түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте «__» _________ күрсәтүне яңадан торгызырга.

Бүлек җитәкчесе _______________________________________
(Ф.И.А.) имза М.У.
Бүлек белгече __________________________________________
(Ф.И.А.) имза
Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:
Язмача______________________________________________________ почта адресы буенча
sms-хәбәр итеп ________________________ телефон номеры буенча
электрон почта буенча _____________________________________________
электрон почта адресы
Бүлек белгече _______________________________________________
(Ф.И.А.) имза».